КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 9 сентябрь г.Казань № 815

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Индустриаль парклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын каплау өчен индустриаль паркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 24 сентябрь, 876 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Индустриаль парклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын каплау өчен индустриаль паркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 24 сентябрь, 876 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 20 декабрь, 1172 нче; 2019 ел, 25 декабрь, 1193 нче; 2020 ел, 22 май, 416 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге карар белән расланган Индустриаль парклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын каплау өчен индустриаль паркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 6, 14, 17 һәм 19 нчы пунктлары нигезләмәсе 2019 елның 24 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.»;

әлеге карар белән расланган Индустриаль парклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын

каплау өчен индустриаль паркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

4 нче пунктның җиденче һәм сигезенче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 4[1] нче пункт өстәргә:

«4[1]. Индустриаль паркның идарә итүче компаниясен сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр була:

Министрлык белән индустриаль парк проектын тормышка ашыру чорын һәм графигын һәм индустриаль паркның финанс-икътисадый күрсәткечләрен күздә тота торган хезмәттәшлек турында килешү булу. Финанс-икътисадый күрсәткечләр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Индустриаль парклар, сәнәгать технопарклары һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын каплау өчен субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтүдән файдалану хокукы булган Россия Федерациясе субъектларын сайлап алу турында» 2014 елның 30 октябрендәге 1119 номерлы карары белән (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1119 номерлы карары) расланган Индустриаль парклар, сәнәгать технопарклары һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын каплау өчен субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтүдән файдалану хокукы булган Россия Федерациясе субъектларын сайлап алу кагыйдәләренең II бүлегендәге 5 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш;

индустриаль (сәнәгать) парклар һәм индустриаль (сәнәгать) паркларның идарә итүче компанияләре реестрында индустриаль (сәнәгать) паркларның һәм индустриаль (индустриаль) парклардагы идарә итүче компанияләренең «Индустриаль (сәнәгать) парклар һәм индустриаль (индустриаль) паркларның идарә итүче компанияләре турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 4 августындагы 794 номерлы карары белән расланган индустриаль (сәнәгать) паркларга һәм индустриаль (индустриаль) паркларның идарә итүче компанияләренә карата таләпләргә туры килүе турында мәгълүматлар булу.»;

8 нче пунктта:

егерменче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлык белән, комплекслы инвестицион проект паспортын теркәп, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1119 номерлы карарының II бүлегендәге 5 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килә торган индустриаль парк проектын тормышка ашыру чорын, графигын һәм финанс-икътисадый күрсәткечләрен күздә тота торган хезмәттәшлек турында килешү;»;

егерме беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Индустриаль (сәнәгать) парклар һәм индустриаль (индустриаль) паркларның идарә итүче компанияләре турында» 2015 елның 4 августындагы 794 номерлы карары белән расланган индустриаль (сәнәгать) паркларга һәм индустриаль (индустриаль) паркларның идарә итүче компанияләренә карата таләпләргә туры килә торган индустриаль (сәнәгать) парклар һәм индустриаль (сәнәгать) паркларның идарә итүче компанияләре реестрыннан өземтә.»;

егерме бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бу пунктның унынчы, унберенче абзацларында күрсәтелгән документлар идарә итүче компания тарафыннан тапшырыла, аңа тапшырылган документларның дәүләт экспертизасыннан уңай бәяләмә бирелгән проект (смета) документларына туры килүен раслый торган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы хаты теркәлә.»;

14 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Министрлык идарә итүче компания белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында килешү, килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү (кирәк булганда) төзи.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

каплау өчен субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлеше;

субсидияне күчерү вакытлары һәм тәртибе;

субсидия күчерелә торган счетлар;

субсидияләр бирү нәтиҗәләренең мәгънәсе;

субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисаплылык бирү вакытлары һәм формалары, аларга түбәндәге хисап документлары теркәлә: дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеше таләпләренә (булганда бирелә) туры килүе турында бәяләмәсе, субсидияләнә торган капиталь төзелеш объектын файдалануга тапшыруга рөхсәтнамә (объектны файдалануга тапшырганнан соң бирелә), шулай ук өстәмә хисаплылык (кирәк булганда);

субсидияне кире кайтару очраклары;

бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турындагы нигезләмәләр;

идарә итүче компаниянең субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы;

кабул ителгән йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешмәгән, шулай ук субсидия бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын бозган өчен идарә итүче компаниянең җаваплылыгы;

субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешмәгәндә кулланыла торган штраф санкцияләре;

проектны тормышка ашыру чорында индустриаль парклар инфраструктурасының субсидияләнә торган объектларын читләштерүгә тыю.

Өстәмә килешү төзү өчен түбәндәгеләр нигез була:

субсидия бирү турындагы килешүне өзү турында карар;

индустриаль паркның финанс-икътисадый күрсәткечләренә төзәтмәләр кертү өлешендә бу Тәртипнең 8 нче пунктындагы егерменче абзацында күрсәтелгән хезмәттәшлек турындагы килешүгә үзгәрешләр кертү;

индустриаль паркның финанс-икътисадый күрсәткечләренә төзәтмәләр кертү өлешендә комплекслы инвестицион проект паспортына үзгәрешләр кертү;

агымдагы елда эшләре дәвам ителгән һәм үткән елда төзелеше, модернизациясе һәм (яки) реконструкциясе өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирелгән индустриаль парклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын каплау өчен идарә итүче компаниягә субсидия бирү турында карар;

индустриаль паркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирүгә бәйле Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин